ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2024 Мөслим ав. № 554

**«Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 3 ноябрендәге 502 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм «НСПД ЕЦП ФГИСтан файдаланып муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлешендә административ регламентларга үзгәрешләр кертү турында» 2024елның 18 октябрендәге 1-31/15348 номерлы Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының хатына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 03 ноябрендәге 502 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3.3.4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3.4 регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»;

1.2. 3.4.5 пунктын яңа редакциядә бирергә:

«3.4.5 регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган системаны кулланып, шул исәптән гаризаны регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәгән вакыттан алып, автомат режимда башкарыла.

Регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында милли пространство белешмәләренең эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»;

1.3. 3.5.4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4 Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән процедуралар, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

! Регламентның 3.5.2 - 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында Пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә»;

1.4. 3.5.5 пунктын түбәндәге редакциядә өстәргә:

«3.5.5 регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь вакыты 14 эш көне тәшкил итә»; !

1.5. 3.6.2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2. документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазифаи зат:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документациясен алып бару ярдәмче системасына һәм (яисә) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмати системасына муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә белешмәләрне теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен органда яисә КФҮтә алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедураларны үтәү техник мөмкинлекләр булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле процедураларны үтәү кысаларында пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Пунктта билгеләнә торган административ процедуралар органның вәкаләтле вазыйфаи заты (орган) тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне (бирүдән баш тартуны) раслый торган документка имза салынган көннән алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре: муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләрне мәгълүмат системаларында урнаштыру, гариза бирүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.

1.6. 2.8.2.1 пунктының 8 нче подпунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«8) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән яки аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә, моңа җир кишәрлеген бирү турында гариза белән бина, корылма, биналар милекчесе, мондый җир кишәрлегендә урнашкан төгәлләнмәгән төзелеш объекты яисә мондый җир кишәрлегенең хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклар керми;»;

1.7. 2.8.2.1 пунктының 9 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

9) җир кишәрлеге федераль әһәмияткә ия объектларны, төбәк дәрәҗәсендәге әһәмияткә ия объектларны яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан булу яисә җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган булу;

1.8. 2.8.2.1 пунктының 10 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«10) җир кишәрлеге җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән яки территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлегеннән төзелгән, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен каралган булса, моңа җир кишәрлеген арендага бирү турындагы гариза белән әлеге затның күрсәтелгән объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тотучы зат мөрәҗәгать иткән булса;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://muslumovo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда: http://pravo.tatarstan.ru. урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

**Башкарма комитет Җитәкчесе** **И.Ф.Салихҗанов**